Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

____28.12.2024____________ Менделеевск ш. № ____774______

Менделеевск муниципаль районы халкына
күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне
карап тоту буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту чаралары һәм алар өчен түләү күләменең нигезлелеге турында» 2010 елның 9 апрелендәге 250 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы буенча торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән һәм йорт белән идарә итү ысулын сайламаган һәм гомуми җыелышта Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы буенча торак урыннарны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны расларга һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 12 июлендәге 431 номерлы карары 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә..

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Килештерелгән:

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф. Искаков

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының төзелеш һәм
торак-коммуналь хуҗалык бүлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы В.П. Колсанов

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының юридик
бүлеге башлыгы Е.С. Царева

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___» _____________20__. ___
номерлы карарына кушымта

МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУЕНЧА СОЦИАЛЬ НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫНА НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯЛЛАУЧЫЛАР, КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ЫСУЛЫН САЙЛАУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН ТОРАК УРЫННАР МИЛЕКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШТА МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТТАГЫ УРЫННАР МИЛЕКЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ТОРАК УРЫННЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) **01.07.2024 елдан 31.12.2024 елга кадәр** | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) **01.01.2025елдан 01.07.2025елга кадәр** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 4,41 | 4,60 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м<br>01.01.2025 елдан - торак урыннан аена. | 1,40 | 150,00 |
| 3 | Йорт яны территориясен тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 3,03 | 3,24 |
| 4 | Чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 1,14 | 1,32 |
| 5 | Дератизация (дезинсекция) | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 0,21 | 0,33 |
| 6 | Торак биналарны ремонтлау һәм карап тоту, территорияне төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 3,05 | 3,35 |
| 7 | Йорт эчендәге инженерлык суүткәргеч-канализация челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 3,02 | 3,20 |
| 8 | үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 2,64 | 2,87 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Газ белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 0,35 | 0,20 |
| 10 | Йорт эчендәге электр челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 1,22 | 1,35 |
| 11. | Лифт җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | Гомуми мәйданы кв.м. | 3,66 | 3,76 |
| 12 | домофон | торак урыннан аена. | 10,00 | 15,00 |
| 13. | вентиляция каналларын агымдагы ремонтлау һәм тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | - | 0,25 |